| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |

ПРИКАЗ № 235/о БОЕРЫК

«29» 12 2017

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясына, "Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре" 2005 елның 06 июлендәге 313 номерлы карарына ярашлы рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларша.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага бу боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган вакыттан ун эш көне эчендә аның Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Түбәндәгеләрне көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының "Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектларын

төзүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2015 елның 14 декабрендәге 222/о номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының "Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында" 2016 елның 29 июнендәге 114/о номерлы боерыгының 1 пункты.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2017 елның "29" 12 №235/о боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Административ регламент), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 5 һәм 5.1 өлешендә һәм башка федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, капиталь төзелеш объектын төзү Татарстан Республикасындагы ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территориясендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта һәм Татарстан Республикасындагы ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объекты үзгәртеп корылган очракта капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр (алга таба – төзелешкә рөхсәт) бирү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: юридик һәм физик затлар, шәхси эшкуарлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүче яисә төзүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәтен үтәүче – Министрлыкның архитектура һәм шәһәр төзү идарәсенең территорияләрне планлаштыру һәм төзеп тутыру бүлеге (алга таба – вәкаләтле бүлек).

1.3.1. Министрлык урнашкан урын: Казан ш., Дзержинский ур., 10 й.

Вәкаләтле бүлекнең урнашкан урыны: Казан ш., Кремль урамы, 13, 3 кат, каб. К302.

Министрлыкның эш графигы: дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 башлап 18.00 кадәр, җомга 9.00 башлап 16.45 кадәр, төшке аш 12.00 башлап 12.45 кадәр.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, Министрлыкның эш көннәрендә.

Җәмәгать транспортында "Кремль" тукталышына кадәр килергә кирәк: 98 номерлы автобус, "Университет" тукталышына кадәр: 8, 10, 10а, 30, 35, 54, 63, 91, 99а номерлы автобуслар; 7, 17, 20, 21 номерлы троллейбуслар.

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Вәкаләтле бүлекнең белешмә телефоннары: (843) 231-15-16, (843) 231-14-28, (843) 231-14-64.

1.3.3. Министрлыкның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – "Интернет" челтәре) рәсми сайты адресы:- http://www.minstroy.tatar.ru, электрон почта адресы: msagkh@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алучы, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) "Интернет" челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.minstroy.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләренә бәйле мәгълүматлар вәкаләтле бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.3.6. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.3.1, 1.3.2, 1.3.3,2.1, 2.3,2.4, 2.5,2.8,2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2005, № 1 (1 өл.), 16 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – РФ ШрК);

"Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон);

"Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында" 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2015, № 29 (1 кисәк), 4344 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының "Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында" 2012 елның 7 маендагы 601

номерлы указы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.) (алга таба – 601 номерлы РФ Президенты указы);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Төзелешкә рөхсәт һәм эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон формада җибәрү турында" 2017 елның 4 июлендәге 788 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 06.07.2017);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының "Төзелешкә рөхсәт рәвешен һәм объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт рәвешен раслау турында" 2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru - 13.04.2015);

"Татарстан Республикасында шәһәр төзү эшчәнлеге турында" 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеше), 1453 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 98-ТРЗ номерлы ТР законы);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре" 2005 елның 06 июлендәге 313 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турында нигезләмә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – Министрлык турында нигезләмә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Төзелешкә рөхсәт һәм эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон формада җибәрү турында" 2017 елның 27 сентябрендәге 729 номерлы карары (Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы http://pravo.tatarstan.ru, 17.10.2017) (алга таба – 729 номерлы ТР МК карары).

1.5. Әлеге Административ регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм тапшыру, мөрәҗәгать итүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе.

Әлеге Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты). Гаризаларның киңәш ителә торган рәвешләре әлеге Административ регламентның 1 нче, 2 нче кушымталарында китерелде.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 5 һәм 5.1 өлешендә һәм башка федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, капиталь төзелеш объектын төзү Татарстан Республикасындагы ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территориясендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта һәм Татарстан Республикасындагы ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объекты үзгәртеп корылган очракта капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр (алга таба – төзелешкә рөхсәт) бирү | РФ ШрК 51 ст., Министрлык турында нигезләмә |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | Министрлык турында нигезләмәнең 3 бүлеге |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Төзелешкә рөхсәт;<br>төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту;<br>төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү;<br>төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәрләмә;<br>төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтудан баш тарту турында хәбәрләмә;<br>төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында хәбәрләмә | РФ ШрК 51 ст. |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт | 1. Төзелешкә рөхсәт бирү яисә бирүдән баш тарту (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту) процедурасын гамәлгә ашыру чоры төзелешкә рөхсәт бирү (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту) турында гариза теркәүгә алынган көннән соң җиде эш көне тәшкил итә.<br>2. Төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү яисә төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту процедурасын гамәлгә ашыру чоры | РФ ШрК 51 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры | мөрәҗәгать итүчедән яисә төзүчедән җир кишәрлекләреннән файдалану хокукының, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының үзләренә күчүе турында, җир кишәрлеге булдыру турында хәбәрләмә теркәүгә алынган көннән соң җиде эш көне тәшкил итә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору каралмаган | |
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 2.5.1. Төзелешкә рөхсәт бирү, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту турында гариза, шулай ук җир кишәрлекләренә хокукларның, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының күчүе турында һәм җир кишәрлеге булдыру турында хәбәрләмә (алга таба – хокук күчүе турында хәбәрләмә) мөрәҗәгать итүче (аның вәкаләтле вәкиле) тарафыннан шәхсән яисә Министрлык адресына почта аша юллап тапшырыла. Гариза яисә хокук күчүе турында хәбәрләмә кулдан, машина ысулы белән яисә компьютер ярдәмендә тутырыла һәм булган очракта мөрәҗәгать итүченең мөһере белән таныклана | РФ ШрК 51 ст., Федераль закон № 82-ФЗ |
| | 2.5.2. Төзелешкә рөхсәт бирү турында, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту турында гариза әлеге Административ регламентның 1 нче, 2 нче кушымталарында китерелгән үрнәктә тутырыла. | РФ ШрК 51 ст. |
| | 2.5.3. Хокук күчүе турында хәбәрләмәдә реквизитлар күрсәтелергә тиеш:<br>1) җир кишәрлекләренә хокук билгеләүче документларныкы, – мондый җир кишәрлекләренә хокуклар күчкәндә;<br>2) җир кишәрлеге булдыру турында карар, әгәр җир законнарына ярашлы рәвештә җир кишәрлеге булдыру турында карарны дәүләт хакимияте башкарма органы яисә җирле үзидарә органы кабул итсә, түбәндәге очракларда: | РФ ШрК 51 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | аларга яисә аларның бирсенә карата төзелешкә рөхсәт бирелгән җир кишәрлекләрен берләштерү юлы белән җир кишәрлеге ясалганда;<br>аларга карата төзелешкә рөхсәт бирелгән җир кишәрлекләрен бүлү, яңача бүлү яки арасыннан бер өлешен аерып чыгару юлы белән җир кишәрлекләре булдырылганда;<br>3) аларга карата төзелешкә рөхсәт бирелгән җир кишәрлекләрен бүлү, яңача бүлү яки арасыннан бер өлешен аерып чыгару юлы белән җир кишәрлекләре булдырылган очракта, капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору планлаштырылган җир кишәрлегенең шәһәр төзү планы;<br>4) РФ ШрК 51 статьясының 21.9 өлешендә каралган очракта, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында карар яисә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында карар | |
| | 2.5.4. Төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза түбәндәгеләр теркәлә:<br>1) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар;<br>2) Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән очракларда, дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), бюджетка карамаган дәүләт фондының идарә органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләти (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән килешү булган очракта, – күрсәтелгән килешү, әлеге килешүне төзүгә нигез булган хокук иясенең җир кишәрлегенә хокукын билгеләүче документлар;<br>3) төзелешкә рөхсәт алуга гариза тапшырылган көнгә кадәр кимендә өч ел элек җир кишәрлегенә бирелгән шәһәр төзү планы, яки, линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты реквизитлары;<br>4) проект документациясендә булган материаллар:<br>а) аңлатма язуы;<br>б) җир кишәрлегенең шәһәр төзү планында күрсәтелгән мәгълүматларга ярашлы рәвештә эшләнгән, капиталь төзелеш объекты урнашкан урынны, аңа машина белән килү һәм үтү юлларын, гавами сервитутларның гамәлдәге зоналары чикләрен, археологик мирас объектларын билгеләп, җир кишәрлеге оештыруның план схемасы; | РФ ШрК 51 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | в) линияле объектның линияле объектларга карата территорияне планлаштыру буенча документация составында расланган кызыл линияләр чикләрендә урнашуын раслаучы җир кишәрлеге оештыруның план схемасы;<br>г) архитектура чишелешләре;<br>д) инженерлык җиһазланышы турында белешмәләр, проектлана торган капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэминат челтәрләренә тоташтыру (технологик ялгау) урыннарын билгеләп, инженерлык-техник тәэминат челтәрләренең җыелма планы;<br>е) капиталь төзелеш объекты төзелешен оештыру проекты;<br>ж) капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү яисә демонтажлау буенча эшләрне оештыру проекты;<br>5) капиталь төзелеш объектының проект документациясенә экспертиза буенча уңай бәяләмә (РФ ШрК 48 статьясының 12.1 өлешендә каралган очракта, төзелешнең аерым этапларына карата), әгәр мондый проект документациясе РФ ШрК 49 статьясы нигезендә экспертизага тиешле булса, РФ ШрК 49 статьясының 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә дәүләт экспертизасы буенча уңай бәяләмә, РФ ШрК 49 статьясының 6 өлешендә каралган очракларда, проект документациясенә дәүләт экология экспертизасы буенча уңай бәяләмә;<br>6) РФ ШрК 49 статьясының 3.5 өлешендә каралган бәяләмә, - модификацияләнгән проект документациясе кулланылган очракта;<br>7) рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору буенча чик дәрәҗә параметрлардан тайпылуга рөхсәт (әгәр төзүчегә мондый рөхсәт РФ ШрК 40 статьясына ярашлы рәвештә бирелгән булса);<br>8) капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләреннән ризалык, – мондый объект үзгәртеп корылган очракта;<br>9) дәүләт (муниципаль) мөлкәтендәге, хокук иясе булып дәүләт (муниципаль) унитар предприятие, дәүләт (муниципаль) бюджет яисә автоном учреждениесе торган капиталь төзелеш объектында реконструкцияләү эшләре әлеге органнарга карата гамәлгә куючы функцияләрен яисә мөлкәтнең милекчелек хокукы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы, бюджетка карамаган дәүләт фондының идарә органы яисә җирле үзидарә органы) булып | |

| | | |
|---|---|---|
| | торучы дәүләт (муниципаль) заказчысы тарафыннан уздырылган очракта, – мондый реконструкцияләүне уздыру турында, шул исәптән реконструкцияләү барышында күрсәтелгән объектка китерелгән зыянны каплау шартлары һәм тәртибе билгеләнә торган, килешү;<br>10) проект документларына дәүләтнеке булмаган экспертиза буенча уңай бәяләмә бирүче юридик затның аккредитация турында таныклык күчермәсе, әгәр проект документациясенә карата дәүләтнеке булмаган экспертиза буенча бәяләмә тапшырылган булса;<br>11) мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнарында каралган документлар, әгәр мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр уздырылганда мондый объектның ышанычлылыгына һәм куркынычсызлыгына кагылышлы конструктив һәм башка сыйфатламалары кузгатылса.<br>Төзелешкә рөхсәт алу өчен кирәкле документлар бер нөсхәдә (төп нөсхәсе яисә күчермәсе) яисә ике нөсхәдә тапшырыла, аның берсе төп нөсхәсе, икенчесе мөрәҗәгать итүче яисә төзүче тарафыннан таныкланган күчермәсе булырга мөмкин. Документлар ике нөсхәдә тапшырылган очракта, тикшерүдән соң төп нөсхәсе мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелә.<br>Төзелешкә рөхсәт алу өчен кирәкле документлар бары тик электрон формада гына, техник мөмкинлек булган очракта тапшырыла:<br>әгәр капиталь төзелеш объектының проект документациясенә экспертиза буенча уңай бәяләмә (РФ ШрК 48 статьясының 12.1 өлешендә каралган очракта, төзелешнең аерым этапларына карата), РФ ШрК 49 статьясының 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә дәүләт экспертизасы буенча уңай бәяләмә, РФ ШрК 49 статьясының 6 өлешендә каралган очракларда, проект документациясенә дәүләт экология экспертизасы буенча уңай бәяләмә электрон формада тапшырылган булса;<br>әгәр капиталь төзелеш объектына проект документлары һәм (яисә) мондый проект документларын әзерләү өчен башкарылган инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре, шулай ук проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздыру өчен кирәкле башка төр документлар электрон формада тапшырылган булса. | 729 номерлы ТР МК карары |
| | 2.5.5. Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту турында | |

| | | |
|---|---|---|
| | карар кабул итү өчен түбәндәге документлар кирәк:<br>1) төзелеш чорлары өлешендә төзәтмәләр кертелгән капиталь төзелеш объекты төзелешен оештыру проекты;<br>2) төзүченең капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча эшләр башлануы турында хәбәрләмә күчермәсе, аны алу турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы тамгасы белән.<br>Хокук күчүе турында хәбәрләмәгә мөрәҗәгать итүче әлеге Административ регламентның 2.5.4 пунктында күрсәтелгән документларның күчермәләрен кушып куярга хокуклы. | |
| | 2.5.6. Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>почта юлламасы белән.<br>Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм документларны, техник мөмкинлек булган очракта, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә "Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте" дәүләт мәгълүмат системасы аша, уртак файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, тапшырырга (җибәрергә) хокуклы. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән | Әлеге Административ регламентның 2.5.4 пунктының 1, 3 һәм 7 пунктчаларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яисә аларда булган белешмәләр) Министрлык тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алына. Әлеге Административ регламентның 2.5.5 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче (төзүче) тарафыннан мөстәкыйль рәвештә җибәрелә, әгәр күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яисә аларда булган белешмәләр) Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрында булмаса. | РФ ШрК 51 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле документларны мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә дә тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Мөрәҗәгать итүчедән югарыда санап үтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча, норматив хокукый актларда каралган очракларда, алар белән килештерү таләп ителә торган һәм бу гамәл дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | РФ ШрК 51 ст. |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган | РФ ШрК 51 ст. |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>1. Төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту нигезләре:<br>әлеге Административ регламентның 2.5.4 пунктында каралган документларның булмавы;<br>тапшырылган документларның капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата төзелешкә рөхсәт алу өчен тапшырылган җир кишәрлегенең шәһәр төзү планын бирү датасына билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, яки, линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә, шулай ук җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану таләпләренә һәм (яисә) Россия Федерациясенең җир законнарына һәм | РФ ШрК 51 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | бүтән законнарына ярашлы рәвештә билгеләнгән чикләмәләргә, рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик дәрәҗә параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве.<br>2. Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтудан баш тарту нигезләре:<br>әгәр капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору эшләре төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту турында гариза тапшырган чор тәмамланганчыга кадәр башланмаса.<br>3. Төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту нигезләре:<br>1) хокук күчүе турында хәбәрләмәдә РФ ШрК 51 статьясының 21.10 өлешендәге 1-4 пунктларына ярашлы рәвештә күздә тотылган документларның реквизитлары булмау, яисә РФ ШрК 51 статьясының 21.13 өлешендә күрсәтелгән очракта, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документның булмавы;<br>2) хокук күчүе турында хәбәрләмәдә күрсәтелгән белешмәләрнең төгәл булмавы;<br>3) капиталь төзелеш объектын планлаштырылганча урнаштыруның капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча төзелешкә рөхсәт алу өчен тапшырылган җир кишәрлегенең шәһәр төзү планын бирү датасына билгеләнгән таләпләргә, җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану таләпләренә һәм (яисә), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 21.7 өлешендә каралган очракта, Россия Федерациясенең җир законнары һәм бүтән законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләргә туры килмәве | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәтен күрсәтү түләүсез нигездә гамәлгә ашырыла. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Мөрәҗәгать итүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтелүне) көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артып китәргә тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамәсен, шул исәптән электрон рәвештә теркәү вакыты | Министрлыкка гариза килгән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтүнең визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларын урнаштыруга һәм җайлаштыруга карата таләпләр. | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм чорлары турында мәгълүмат стендларында, "Интернет" челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында тулы мәгълүмат булу; | 880 номерлы ТР МК карарының 2.4 п., 601 номерлы РФ Президенты указы |

| | | |
|---|---|---|
| күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | инвалидларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрнең булмавы белән сыйфатлана:<br>документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләр аларны тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү вакытларын бозулар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләренең мөрәҗәгать итүчеләргә карата дорфа, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Мөрәҗәгать итүченең Бүлек белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>Мөрәҗәгать итүче белән эшләү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ), КФҮ читтән торып эшләү урынында күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткән очракта алынырга мөмкин.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан "Интернет" челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтыннан, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге юк | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре, шул исәптән дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталларыннан файдаланып | Дәүләт хезмәте алу турында гаризаны "Татарстан Республикасы Хөкүмәте Порталы" мәгълүмат системасы аша Татарстан Республикасы Хөкүмәте Порталының Интернет-кабул итү системасы аша электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге бар.<br>Техник мөмкинлек булганда документлар электрон формада "Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте" дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрелергә мөмкин.<br>Гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша тапшыру мөмкинлеге юк. | РФ ШрК 51 ст., 729 номерлы ТР МК карары |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) төзелешкә рөхсәтләр бирү турында гаризаларны кабул итү һәм теркәү;

3) гаризаны карау һәм тапшырылган документларның комплектлы булу-булмавын тикшерү;

4) ведомствоара электрон хезмәттәшлекләр;

5) төзелешкә рөхсәтләр бирү турында (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту турында, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында) карар әзерләү;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

7) техник хаталарны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге турында блок-схема әлеге Административ регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелде.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Мөрәҗәгать итүче вәкаләтле бүлеккә язмача формада, Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы (http://www.minstroy.tatar.ru) аша электрон хәбәр итү формасында яисә вазыйфаи затка шәхсән мөрәҗәгать итү формасында дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтле бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча, һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү буенча һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләрдә консультацияләү һәм ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

3.3. Төзелешкә рөхсәтләр бирү турында, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту турында, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында

гаризаларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы заты аша яисә почтадан дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшыра һәм, әлеге Административ регламентның 2.5 пунктына ярашлы рәвештә, Министрлыкның оештыру-беркетмә эше, контрольлек һәм эш башкару бүлегенә документлар тапшыра.

Документларны тапшырганда гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге, шулай ук әлеге Административ регламентның 2.5 пунктына ярашлы рәвештә тапшырылмый торган документларның да исемлеге төзелә.

Тапшырылмый торган документлар исемлегендә аларны биргән органнарның атамалары, теркәлү номерлары, теркәлү даталары, аерым очракларда, тиешле гарызнамәләрне тапшыру өчен кирәкле, аларда булган белешмәләр күрсәтелә.

Гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны, шулай ук хокук күчүе турында хәбәрләмәне мөрәҗәгать итүче, шәһәр төзү эшчәнлеге турындагы законнарда һәм әлеге Административ регламентта билгеләнгән таләпләрне үтәп, электрон формада тапшырырга хокуклы.

Документлар электрон формада тапшырылган очракта, гариза һәм аңа теркәлә торган документлар, шулай ук хокук күчүе турында хәбәрләмә гаризага кул куйган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган булырга тиеш.

3.3.2. Министрлыкның оештыру-беркетмә эше, контрольлек һәм эш башкару бүлеге белгече гаризаны һәм документларны, шулай ук хокук күчүе турында хәбәрләмәне Министрлыкның эш башкару күрсәтмәсендә билгеләнгән тәртиптә теркәүгә ала һәм карау өчен вәкаләтле бүлеккә юллый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формалы гариза вәкаләтле бүлеккә электрон почта буенча яисә Интернет-кабул итү аша җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар Министрлыкка килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза һәм документлар.

3.3.3. Вәкаләтле бүлекнең дәүләт хезмәте күрсәтү бурычы йөкләнгән вазыйфаи затлары (алга таба – Бүлек белгечләре) Төзелешкә рөхсәтләр бирү (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү) турында гаризаларны, хокук күчүе турында хәбәрләмәләрне теркәү журналын (алга таба – Журнал) алып бара.

Журналда түбәндәгеләр күрсәтелә:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тапшырылу датасы (Министрлыкка килү датасы);

мөрәҗәгать итүченең аталышы;

документларны кабул иткән вәкаләтле структур бүлекчәдәге вазыйфаи затның фамилиясе һәм инициаллары;

объектның аталышы һәм килгән документларның (папкаларның, тартмаларның һ.б.) кәгазьләр саны;

төзелешкә рөхсәт әзерләү датасы;

мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәтне (төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тартуны) тапшыру датасы яисә почтадан юллау датасы;

төзелешкә рөхсәт (документларны теркәп, төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту) алган затның имзасы;

төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту турында карар әзерләү датасы;

мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтудан баш тарту) турында хәбәрләмә тапшыру датасы яисә почта аша юллау датасы;

төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар әзерләү датасы;

мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү (төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту) турында хәбәрләмә тапшыру датасы яисә почта аша юллау датасы;

искәрмә.

Журнал кулдан язып һәм электрон формаларда, әлеге Административ регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы рәвештә алып барыла.

Бүлек белгечләре килгән гариза турында белешмәләрне Журналга кертә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза белән документлар Министрлыкка килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Журналдагы язу.

3.4. Гаризаны карау һәм тапшырылган документларның комплектлы булу-булмавын тикшерү.

3.4.1. Бүлек белгечләре тапшырылган документлар җыелмасын әлеге Административ регламентның 2.5 пункты таләпләренә туры килү-килмәвенә тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар килгән гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган документларның комплектлылыгын билгеләү.

3.4.2. Әлеге Административ регламентның 2.5 пункты таләпләренә ярашлы рәвештә гаризага теркәлә торган, төзелешкә рөхсәт алу, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту һәм төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге булмаган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлык компетенциясенә кермәгән төзелешкә рөхсәт бирү турында гаризаны җибәргән очракта, Бүлек белгечләре төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтудан, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында хәбәрләмәне, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының имзасы белән, мөрәҗәгать итүчегә хат белән җибәрәләр яисә кул куйдыртып тапшыралар һәм тиешле язуларны Журналга теркиләр.

Төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтудан, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында хәбәрләмә белән берлектә мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкилләренә) ул тапшырган барлык документлар да кайтарып бирелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач өч эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә

рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтудан, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту һәм мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

3.5. Ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.5.1. Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документлар килгәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булмаган очракта, Бүлек белгечләре дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарга, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарга, дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы органнарга, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга, ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнашучы башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә ярашлы рәвештә белешмәләр алу өчен ведомствоара гарызнамәләр җибәрәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Административ регламентның 3.4.1 пунктындагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тиешле органнарга юлланган гарызнамәләр.

3.5.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнашучы органнар әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны билгеләнгән чорда бирәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнашучы органга гарызанмә килгән көннән соңгы өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гарызнамәләргә җаваплар яисә мәгълүмат булмавы турында хәбәр итү.

3.6. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Бүлек белгечләре проект документларының капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата төзелешкә рөхсәт алу өчен тапшырылган җир кишәрлегенең шәһәр төзү планын бирү датасына билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен, яисә, линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә, шулай ук җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга һәм Россия Федерациясенең җир законнарында һәм бүтән законнарында билгеләнгән чикләмәләргә ярашлы рәвештә капиталь төзелеш объектын урнаштыруның мөмкин булу-булмавын тикшерәләр. Затка рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору буенча чик дәрәҗә параметрлардан тайпылуга рөхсәт ителгән очракта, проект документларына яисә җир кишәрлеген планда оештыру схемасына рөхсәтле төзелешнең, үзгәртеп коруның чик дәрәҗә параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве буенча тикшерү уздырыла.

Тапшырылган документлар түбәндәгеләргә туры килү-килмәү буенча тикшерелә:

1) җир кишәрлегенең шәһәр төзү планында билгеләнгән, түбәндәгеләрне билгели торган параметрларына:

а) җир кишәрлегенең чикләре;

б) гавами сервитутларның гамәлдә булу зоналары чикләре;

в) алардан читтә биналар, төзелмәләр, корылмалар төзелеше башланып киткән биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны мөмкин булганча урнаштыру урыннарын билгеләү максатларында җир кишәрлеге чикләреннән минималь чигенүләр;

г) җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану турында мәгълүмат;

д) күрсәтелгән җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектының билгеләнешенә, параметрларына һәм урнаштырылуына карата таләпләр;

е) җир кишәрлеге чикләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектлары, мәдәни мирас объектлары турында мәгълүмат;

ж) капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэминат челтәрләренә тоташтыруның техник шартлары турында мәгълүмат;

з) дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен капиталь төзелеш объектларын планлаштырылганча урнаштыру зоналары чикләре;

2) территорияне планлаштыру проекты составында расланган кызыл линияләргә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Административ регламентның 3.5.1 пунктындагы процедура тәмамланганнан соң өч эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тикшерелгән проект документациясе.

3.6.2. Тапшырылган документлар капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата төзелешкә рөхсәт алу өчен тапшырылган җир кишәрлегенең шәһәр төзү планын бирү датасына билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәгәндә, яки, линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә, шулай ук җир кишәрлегеннән рөсхәтле файдалануга һәм Россия Федерациясенең җир законнары һәм бүтән законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләргә ярашлы рәвештә капиталь төзелеш объектын урнаштыруның мөмкин булуына, территорияне планлаштыру проекты составында расланган кызыл линияләргә, шулай ук рөхсәт ителгән төзелеш яисә үзгәртеп кору буенча чик дәрәҗә параметрлардан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәгән очракта, Бүлек белгечләре төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтудан, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында хәбәрләмә әзерлиләр һәм, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының имзасы белән, мөрәҗәгать итүче (аның вәкаләтле вәкиле) адресына җибәрәләр.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтудан, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән хат.

3.6.3. Тапшырылган документлар капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата төзелешкә рөхсәт алу өчен тапшырылган җир кишәрлегенең шәһәр төзү планын бирү датасына билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәгәндә, яки, линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта,

территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә, шулай ук җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга һәм Россия Федерациясенең җир законнары һәм бүтән законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләргә ярашлы рәвештә капиталь төзелеш объектын урнаштыруның мөмкин булуына, территорияне планлаштыру проекты составында расланган кызыл линияләргә, шулай ук рөхсәт ителгән төзелеш яисә үзгәртеп кору буенча чик дәрәҗә параметрлардан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә җавап биргән очракта, төзелешкә рөхсәт бирү өчен җаваплы булган Бүлек белгечләре:

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының "Төзелешкә рөхсәт формасын һәм объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт формасын раслау турында" 2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы боерыгы белән расланган форма буенча төзелешкә рөхсәт, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтуга, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүгә рөхсәт әзерлиләр. Төзелешкә рөхсәт ике нөсхәдә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының имзасы белән әзерләнә, аларның берсе мөрәҗәгать итүчегә тапшырыла, икенчесе Министрлык архивында саклана. Төзелешкә рөхсәт әлеге Административ регламентның 4 нче кушымтасына ярашлы рәвештә Төзелешкә тапшырылган рөхсәтләр реестрында (алга таба – Реестр) аерым тәртип номеры белән исәпкә алына;

гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итәләр, рәсмиләштерелгән рөхсәтне (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтуның, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүне рәсмиләштерүнең) датасы һәм вакыты турында җиткерәләр;

төзелешкә рөхсәтләр бирү турында (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту турында, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында) карарны Журналда теркиләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар документларның законнардагы таләпләргә ярашлы булу-булмавы тикшерү тәмамланганнан соң (әлеге Административ регламентның 3.6.1. пунктында каралган процедура тәмамлангангач) бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: төзелешкә рөхсәт (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү), мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.6.4. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) төзелешкә рәсмиләштерелгән рөхсәтне (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтуны, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүне) төзелешкә рөхсәтне алу турында төзелешкә тапшырылган рөхсәтләр журналында кул куйдыртып тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне, чират тәртибендә, 15 минут дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: төзелешкә бирелгән рөхсәт (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү).

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булып торучы документта техник хата

ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче вәкаләтле бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (6 нчы кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булып торучы документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә) җибәрелә.

3.7.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны кушып тапшырылган документлары белән бергә терки һәм аларны вәкаләтле бүлеккә тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза.

3.7.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында, әлеге Административ регламентның 3.6.3 пунктында каралган процедураларны башкара һәм яңадан үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкиленә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкиленнән) техник хатасы булган документның чын нөсхәсен алып калып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша Бүлеккә техник хатасы булган документның чын нөсхәсен тапшырган очракта документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

3.8. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрнең читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Административ регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы (алга таба – Идарә) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Көндәлек тикшереп тору Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Административ регламентта һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели

торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, гариза тапшыручыларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең Министрлыктагы вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эш башкаруның алып барылышы, шул исәптән документларны кабул итү вакытларының һәм тәртибенең үтәлеше;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (әлеге Административ регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары, тәртибе үтәлүе.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Министрлык актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Административ регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгеле торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) физик һәм юридик затлар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Тикшереп тору нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, Россия Федерациясе законнары нигезендә гаепле затларны җаваплылыкка тарту гамәлгә ашырыла.

4.8. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

### 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук андагы дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар судка кадәр тәртиптә вәкаләтле бүлекнең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Идарә җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Идарә җитәкчесе кабул иткән карарларга шикаятьләр Министрлыкка тикшереп торучы министр урынбасары исеменә яисә министр исеменә, министр урынбасары (министр) тарафыннан кабул ителгән карарларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризасын теркәү вакыты бозылганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тарту;

федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән бүтән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту;

дәүләт хезмәте яисә муниципаль хезмәтне күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның, яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органындагы вазыйфаи затның дәүләт хезмәте яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарын төзәтүдән баш тартуы очрагында яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почтадан, КФҮ аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://minstroy.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш

тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять кылына торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең аталышы;

2) мөрәҗәгать итүче-физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны яисә мөрәҗәгать итүче-юридик затның аталышы, мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр. Шулай ук мөрәҗәгать итүчегә җавап бирелергә мөмкин булган элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) яисә почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять кылына торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.7. Шикаятьләр аны тапшыручы дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан имзалана.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Административ регламентның 5.1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи зат түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук бүтән рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына1 нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы
кемнән:____________________________________________
( төзелешне, үзгәртеп коруны планлаштыручы
____________________________________________
юридик зат-төзүченең атамасы,
____________________________________________
ИНН; юридик яисә почта адресы;
____________________________________________
житәкчесенең Ф.И.А.; телефоны;
____________________________________________
банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК))

# Төзелешкә рөхсәт бирү турында ГАРИЗА

Төзүгә/үзгәртеп коруга рөхсәт бирүне сорыйм
____________________________________________
(кирәклесе астына сызарга);
____________________________________________
(объектның аталышы)

түбәндәге адрес буенча җир кишәрлегендә урнашкан:
____________________________________________
(шәһәр, район, урам, кишәрлек номеры)
____________________________________________
____________________________________________

______________________ айлык чорга кадәр.

Төзелеш (үзгәртеп кору) түбәндәгегә нигезләнеп гамәлгә ашырылачак: _____ елның "___"_____________ №_______________ ______________________________.
(документ исеме)

Җирдән файдалану хокукы
беркетелде____________________________________________
(документ исеме)
____________________________________ _____ елның "____"__________ № _________.

Объект төзелешенең проект документлары эшләнде
____________________________________________
____________________________________________
(оешманың аталышы, ИНН, юридик һәм почта адреслары,
____________________________________________
житәкчесенең Ф.И.А., телефон номеры, банк реквизитлары
____________________________________________
реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК))

проект эшләрен башкаруга хокукы булган, түбәндәге белән
беркетелгән____________________________________________
____________________________________________
(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың аталышы)

_____ елның "____"______________№______________, һәм билгеләнгән тәртиптә мәнфәгатьле оешмалар һәм архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары белән килештерелде:

– дәүләт экспертизасы буенча уңай бәяләмә № _________ _______ елның "___"__________________.

җир кишәрлеген планда оештыру схемасы ________________________________________

(оешманың аталышы)

белән килештерелде, ___ елның "___"_________ № __________.

Проект документациясе расланды ____________________________________________

___________________________________ № ____, ___________елның "___" ________________.

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

Төзүче тарафыннан төзелешне (үзгәртеп коруны) финанслау түбәндәгечә гамәлгә ашырылачак ____________________________________________

(банк реквизитлары һәм счет номеры)

Эшләр 20___ елның "___"______________ № _____ шартнамә нигезендә подряд (хуҗалык) ысулы белән башкарылачак.

____________________________________________

(оешманың аталышы, ИНН,

____________________________________________

юридик һәм почта адреслары, җитәкчесенең ФИА, телефон номеры,

____________________________________________

банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК))

Төзү-монтажлау эшләрен башкару хокукы беркетелде ____________________________________________

____________________________________________

(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың аталышы)

____________________________________________

«____»___________________ ел, №______________________

_______________________________________ "___"___________ ел, №____________ боерык

(вазыйфа, фамилия, исем, ата исеме)

нигезендә эшләрне башкаручы итеп билгеләнде.

______________________ махсус белеме һәм төзелештә_________ел эш стажы бар.

(югары, урта),

Төзелеш контрольлеге "___"________ ел, № _____________ шартнамә нигезендә түбәндәге тарафыннан гамәлгә ашырылачак:

____________________________________________

(оешманың аталышы, ИНН, юридик һәм

____________________________________________

почта адреслары, җитәкчесенең ФИА, телефон номеры, банк

____________________________________________

реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

заказчы (төзүче) функцияләрен башкару хокукы беркетелде:______________________________________

____________________________________________

(документ исеме һәм аны биргән оешма аталышы)

№ ____________ "____"___________________ ел.

Әлеге гаризада китерелгән белешмәләргә бәйле барлык үзгәрешләр турында ______________________________________ хәбәр итәргә сүз бирәм.
(вәкаләтле орган атамасы)

________________________________________________________________________________

_________________ _______________ ____________________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.)

"___"_____________20_____ ел.
М.У.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы
кемнән:______________________________________________
(юридик зат-төзүченең атамасы),
_______________________________________________________
төзелешне, үзгәртеп коруны планлаштыручы;
_______________________________________________________
ИНН; юридик яисә почта адресы;
_______________________________________________________
житәкчесенең Ф.И.А.; телефоны;
_______________________________________________________
банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

## Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту турында ГАРИЗА

_____________________________________________________________________ адресы буенча
(шәһәр, район, урам, кишәрлек номеры)
урнашкан ____________________________________________________ төзүгә/үзгәртеп коруга
(объектның аталышы) (кирәклесе астына сызарга);
20___ елның "_____"______________ № __________ рөхсәтнең гамәлдә булу чорын___________ айлык чорга кадәр озынайтуны сорыйм.

Төзелеш (үзгәртеп кору) түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:
_______________________ "____" _____________________ ел, № _______.
(документ исеме)

Җирдән файдалану хокукы беркетелде:_________________________________________
(документ исеме)
_________________________________________ _____ елның "____"_________ № _____.

Объект төзелешенең проект документлары эшләнде:___________________________________
_______________________________________________________________________________
(оешманың аталышы, ИНН, юридик һәм почта адреслары,
_______________________________________________________________________________
житәкчесенең Ф.И.А., телефон номеры, банк реквизитлары
_______________________________________________________________________________
(банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)
проект эшләрен башкаруга хокукы булган, түбәндәге белән беркетелгән:_____________________
_______________________________________________________________________________
(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың аталышы)

_____ елның "____"______________№______________, һәм билгеләнгән тәртиптә
Мәнфәгатьле оешмалар һәм архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары белән килештерелде:

- дәүләт экспертизасы буенча уңай бәяләмә № _________ _______ елның "___"_________________ алынды.
- җир кишәрлеген планда оештыру схемасы ____________________________________
(оешманың аталышы)

белән килештерелде, ___ елның "___"_________ № __________.

Проект-смета документациясе расланды ____________________________________

_________________________________________ № ____, ___________елның "___" ________________.

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

Төзүче тарафыннан төзелешне (үзгәртеп коруны) финанслау түбәндәгечә гамәлгә ашырылачак

_______________________________________________________________________________

(банк реквизитлары һәм счет номеры)

Эшләр 20___ елның "___"______________ № _____ шартнамә нигезендә подряд (хуҗалык) ысулы белән башкарылачак.

_______________________________________________________________________________

(оешма атамасы, ИНН,

_______________________________________________________________________________

юридик һәм почта адреслары, җитәкчесенең ФИА, телефон номеры,

_______________________________________________________________________________

банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

Төзү-монтажлау эшләрен башкару хокукы беркетелде ______________________________________

_______________________________________________________________________________

(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың аталышы)

_______________________________________________________________________________

“____” ____________________ ел, №________________________

“___”_________ ел, № ____ боерык нигезендә эшләрне башкаручы итеп___________________ _____________________________________________________ билгеләнде. Аның _______________

(вазыйфа, фамилия, исем, ата исеме) (югары, урта)

махсус белеме һәм төзелештә ________ еллык эш стажы бар.

Төзелеш контрольлеге "___"________ ел, № _____________ шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла

_______________________________________________________________________________

(оешманың аталышы, ИНН, юридик һәм

_______________________________________________________________________________

почта адреслары, җитәкчесенең ФИА, телефон номеры, банк

_______________________________________________________________________________

реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

заказчы (төзүче) функцияләрен башкару хокукы беркетелде

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(документ исеме һәм аны биргән оешма аталышы)

№ ____________ "____" ____________________ ел.

Әлеге гаризада китерелгән белешмәләргә бәйле барлык үзгәрешләр турында _____________________________ хәбәр итәргә сүз бирәм.

(вәкаләтле орган атамасы)

_______________________________________________________________________________


_________________ _______________ ____________________

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.)

"___"______________20_____ ел.

М.У.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта



Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Капиталь төзелеш объектлары төзелешенә бирелгән рөхсәтләр реестры

| № п/п | Керүче документның номеры һәм датасы | Мөрәҗәгать итүченең аталышы | Объектның исеме | Дата һәм рөхсәт номеры | Рөхсәтнең гамәлдә булу чоры | Чыга торган документның номеры һәм датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

## Төзелешкә рөхсәтләр бирү (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту) турында гаризаларны теркәү журналы

| № п/п | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тапшырылу датасы (Министрлыкка килү датасы) | Мөрәҗәгать итүченең (хокук кучү турында хәбәрләмәдә күрсәтелгән затның) исеме | Документларны кабул иткән вәкаләтле структур бүлекчәдәге вазыйфаи затның фамилиясе һәм инициаллары | Объектның исеме | Төзелешкә рөхсәт әзерләү датасы/ төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту турында карар әзерләү датасы/төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар әзерләү датасы | Мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәтне тапшыру (төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту)/ мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтудан баш тарту) турында хәбәрләмә тапшыру датасы яисә почтадан юллау датасы/ мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү (төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту) турында хәбәрләмә тапшыру яисә почтадан юллау датасы | Төзелешкә рөхсәт (төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту) алган затның имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы
кемнән:________________________________________
(юридик зат-төзүченең атамасы),
________________________________________
төзелешне, үзгәртеп коруны планлаштыручы;
________________________________________
ИНН; юридик яисә почта адресы;
________________________________________
җитәкчесенең Ф.И.А.; телефоны;
________________________________________
банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

Техник хата төзәтү турында
ГАРИЗА

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ________________________________________
(хезмәтнең аталышы)

Язылган:________________________________________
________________________________________

Дөрес белешмәләр:________________________________________
________________________________________

Техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны:

e-mail:________________________ адресына электрон документ рәвешендә;

кәгазьдә почта юлламасы итеп түбәндәге адрес буенча:
________________________________________җибәрүне сорыйм.

Хәзергесе белән шунысын раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм

минем тарафтан вәкил булган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

| | | |
|---|---|---|
| ________________ | __________________ | ( __________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А.) |

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы

| Вазыйфасы | **Телефоны** | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министрның беренче урынбасары | (843) 231-14-05 | A.AS@tatar.ru |
| Министр урынбасары | (843) 231-15-07 | Vladimir.Kudryashev@tatar.ru |
| Идарә башлыгы | (843) 231-15-57 | G.Zagidullina@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | (843) 231-15-16 | Olga.Kaynova@tatar.ru |
| Бүлек белгечләре | (843) 231-14-64<br>(843) 231-14-28 | Lyudmila.Sibatrova@tatar.ru<br>Irina.Valeeva@tatar.ru<br>I.Nigmatullina@tatar.ru<br>V.Z.I@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестицияләү программаларын тормышка ашыру буенча бүлек башлыгы | (843) 264-77-24 | Yuriy.Azin@tatar.ru |